СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 2-3 от «16» ноября 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Мамадыш муниципаль Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2009 елның 31 октябрендәге 10-35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.13 пунктындагы «муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)» сүзләрен «муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планнары (программалары)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет, икътисад сәясәте һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

2

000100